ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ КАЙБИЦКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

17.04.2023 Олы Кайбыч ав. № 148

«2021-2024 елларга Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районында хокук бозуларны профилактикалау буенча комплексы программаны раслау турында» 2020 елның 24 октябрендәге 545 номерлы карары белән расланган 2021-2024 елларга Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районында хокук бозуларны профилактикалау буенча комплексы программага үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясе субъектларында гавами хакимият оештыруның гомуми принциплары турында» 2021 елның 21 декабрендәге 414-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасы Конституциясенә үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 26 гыйнварындагы 1-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Башкарма комитеты түбәндәгеләрне КАРАР ИТӘ:

1. «2021-2024 елларга Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районында хокук бозуларны профилактикалау буенча комплексы программаны раслау турында» 2020 елның 24 октябрендәге 545 номерлы карары белән расланган 2021-2024 елларга Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районында хокук бозуларны профилактикалау буенча комплексы программага түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1.2 пунктның беренче абзацында «Президенты» сүзен «Башлыгы (Рәисе)» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (https://kaibici.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә) һәм Кайбыч муниципаль районының рәсми сайтында (https://kaibici.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты эшләре идарәчесе Д.Ә.Бәдертдиновага йөкләргә.

Җитәкче А. Н. Макаров